КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 11 май г.Казань № 377

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисадый зоналарында коммерциячел булмаган оешмаларның муниципальара ресурс үзәкләре эшләвенә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен һәм Татарстан Республикасы коммерциячел булмаган оешмаларының мәгълүмати порталын тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 5 июнь, 339 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисадый зоналарында коммерциячел булмаган оешмаларның муниципальара ресурс үзәкләре эшләвенә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен һәм Татарстан Республикасы коммерциячел булмаган оешмаларының мәгълүмати порталын тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 5 июнь, 339 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 22 май, 429 нчы; 2019 ел, 2 сентябрь, 744 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2021» саннарын «2024» саннарына алыштырырга;

2 нче пунктта «, субсидия бирү турында килешү, субсидиядән файдалану турында хисап» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының икътисадый зоналарында коммерциячел булмаган оешмаларның муниципальара ресурс үзәкләре эшләвенә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибендә:

2 нче пунктта «2021» саннарын «2024» саннарына алыштырырга;

3 нче пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«коммерциячел булмаган оешманың салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаска тиеш;»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«коммерциячел булмаган оешма үзгәртеп оештыру, ябылу процессында тормаска, аңа карата банкротлык процедурасы башланмаска, коммерциячел булмаган оешма эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмаска тиеш;»;

5 нче пунктта:

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«коммерциячел булмаган оешманың үзгәртеп оештыру, ябылу процессында тормавы, аңа карата банкротлык процедурасы башланмавы, коммерциячел булмаган оешма эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмавы һәм хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга чикләүләре булмавы турында коммерциячел булмаган оешма җитәкчесе имзалаган гарантия хаты.»;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты алдында үз вакытында түләнмәгән бурычлары булмавын раслый торган документны вәкаләтле орган ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша соратып ала.»;

7 нче пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) коммерциячел булмаган оешма тарафыннан кертелгән документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.»;

11 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

субсидия аларның финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнар юнәлешләре;

субсидия бирү нәтиҗәләренең һәм субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләрнең мәгънәләре;

субсидияне күчерү тәртибе;

субсидия бирү нәтиҗәләренең һәм субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләрнең мәгънәләренә ирешү турында, субсидия аларның финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнар хакында хисаплылык, шулай ук өстәмә хисаплылык (кирәк булганда) бирү тәртибе, вакытлары һәм формалары;

Килешүгә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә өстәмә килешүләр төзү нигезләре, шартлары һәм тәртибе;

агымдагы финанс елында коммерциячел булмаган оешма тарафыннан хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешләрен кире кайтару очраклары;

Акча белән баш эш итүче тарафыннан, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, субсидиянең калган өлешләрен файдалануга ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгәндә хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешләре аларның финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тота торган шарт;

алган акча исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны (Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә югары технологияле импорт җиһазы, чимал һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (кайтартканда) гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук әлеге акчаны бирү максатларына ирешүгә бәйле башка операцияләрдән тыш) тыю турында нигезләмәләр;

коммерциячел булмаган оешманың һәм субсидияләр бирү турында шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, үтәүчеләр) булган затларның Акча белән баш эш итүче һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан коммерциячел булмаган оешманың субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы;

коммерциячел булмаган оешма тарафыннан бу Тәртип һәм Килешү шартлары үтәлеше турында нигезләмәләр;

коммерциячел булмаган оешманың кабул ителгән йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыгы, шул исәптән коммерциячел булмаган оешма тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе бозылган өчен (кирәк булганда кулланыла торган) штраф санкцияләре.»;

түбәндәге эчтәлекле $11^1$ нче пункт өстәргә:

«$11^1$. Коммерциячел булмаган оешма килешүдә билгеләнгән вакытларда һәм формада Акча белән баш эш итүчегә субсидия аларның финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнар турында хисап һәм субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү хакында хисап кертә.»;

13 нче пунктта «өч көн эчендә» сүзләрен «10 көн эчендә» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы коммерциячел булмаган оешмаларының мәгълүмати порталын тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибендә:

2 нче пунктта «2021» саннарын «2024» саннарына алыштырырга;

3 нче пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

3 нче пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«коммерциячел булмаган оешманың салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаска тиеш;»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«коммерциячел булмаган оешма үзгәртеп оештыру, ябылу процессында тормаска, аңа карата банкротлык процедурасы башланмаска, коммерциячел булмаган оешма эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмаска тиеш;»;

5 нче пунктта:

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«коммерциячел булмаган оешманың үзгәртеп оештыру, ябылу процессын-да тормавы, аңа карата банкротлык процедурасы башланмавы, коммерциячел булмаган оешма эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмавы һәм хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга чикләүләре булмавы турында коммерциячел булмаган оешма җитәкчесе имзалаган гарантия хаты.»;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты алдында үз вакытында түләнмәгән бурычлары булмавын раслый торган документны вәкаләтле орган ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша соратып ала.»;

7 нче пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) коммерциячел булмаган оешма тарафыннан кертелгән документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.»;

11 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

субсидия аларның финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнар юнәлешләре;

субсидия бирү нәтиҗәләренең һәм субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләрнең мәгънәләре;

субсидияне күчерү тәртибе;

субсидия бирү нәтиҗәләренең һәм субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләрнең мәгънәләренә ирешү турында, субсидия аларның финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнар хакында хисаплылык, шулай ук өстәмә хисаплылык (кирәк булганда) бирү тәртибе, вакытлары һәм формалары;

Килешүгә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә өстәмә килешүләр төзү нигезләре, шартлары һәм тәртибе;

агымдагы финанс елында коммерциячел булмаган оешма тарафыннан хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешләрен кире кайтару очраклары;

Акча белән баш эш итүче тарафыннан, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, субсидиянең калган өлешләрен файдалануга ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгәндә хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешләре аларның финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тота торган шарт;

алган акча исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны (Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә югары технологияле импорт җиһазы, чимал һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (кайтартканда) гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук әлеге акчаны бирү максатларына ирешүгә бәйле башка операцияләрдән тыш) тыю турында нигезләмәләр;

коммерциячел булмаган оешманың һәм субсидияләр бирү турында шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, үтәүчеләр) булган затларның Акча белән баш эш итүче һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан коммерциячел булмаган оешманың субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы;

коммерциячел булмаган оешма тарафыннан бу Тәртип һәм Килешү шартлары үтәлеше турында нигезләмәләр;

коммерциячел булмаган оешманың кабул ителгән йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыгы, шул исәптән коммерциячел булмаган оешма тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе бозылган өчен (кирәк булганда кулланыла торган) штраф санкцияләре.»;

түбәндәге эчтәлекле $11^1$ нче пункт өстәргә:

«$11^1$. Коммерциячел булмаган оешма Акча белән баш эш итүчегә килешүдә билгеләнгән вакытларда һәм формада субсидия аларның финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнар турында хисап һәм субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү хакында хисап кертә.»;

13 нче пунктта «өч көн эчендә» сүзләрен «10 көн эчендә» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин